РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. А.Валеева, д. 50, Азнакаевский район,
с .Ильбяково, 423338,
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
Башлыгы

Ә.Вәлиев ур., 50 йорт, Азнакай районы,
Илбәк авылы, 423338
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**7 март 2024 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Тархан торак пунктында гражданнар җыенының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Тархан авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы карарына, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Тархан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына ярашлы, 35 «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.11.2023 № 1532 карары белән «2024 елда Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында», Илбәк авыл җирлеге Уставының 15.1 маддәсе нигезендә, Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы карар кабул итте:

1. Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Тархан торак пунктында «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Тархан авылында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү турында» 2023 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Тархан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 18 мартындагы 13 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертүгә ризамы:

а) "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Тархан авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында" 2023 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы карарының 1, 2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Тархан авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы

буенча белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнардан тыш, 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 750 сумга киметеп, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту (Тархан авылындагы юлларны кардан чистарту; вак ташны сатып алу, ташу, Лесная, Заречная урамнарына вак ташны җәю, эшкә килешү буенча түләү, тракторчыга хезмәт хакын түләү).

б) «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Тархан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы карары:

преамбулада «түбәндәге эшләрне башкару буенча:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту (Тархан авылындагы юлларны кардан чистарту; вак ташны сатып алу, ташу, Лесная, Заречная урамнарына вак ташны җәю, эшкә килешү буенча түләү, тракторчыга хезмәт хакын түләү).» сүзләрен «түбәндәге эшләрне башкару буенча:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Тархан авылындагы юлларны кардан чистартучы тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәте өчен, кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү; вак ташны сатып алу, ташу, Лесная, Заречная урамнарына вак ташны җәю (эшкә килешү буенча түләү)).» сүзләре белән алмаштырырга.

- 2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез, 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Тархан авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнардан тыш, 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 750 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту (Тархан авылындагы юлларны кардан чистарту; вак ташны сатып алу, ташу, Лесная, Заречная урамнарына вак ташны җәю, эшкә килешү буенча түләү, тракторчыга хезмәт хакын түләү).

« ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының мәгълүмат стендларында һәм http://aznakayevo.tatarstan.ru адресы буенча рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Башлык Р.К.Галимҗанова